| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** 08.08.2019 г.Зеленодольск **КАРАР** № 252

Зеленодольск шәһәре Советының «2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 93 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (Зеленодольск шәһәре Советының 2019 елның 26 апрелендәге 241 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск шәһәре Советы карар итте:

1.Зеленодольск шәһәре Советының «2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 93 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (Зеленодольск шәһәре Советының 2019 елның 26 апрелендәге 241 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән):

1) 1нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.5.1нче пунктча өстәргә:

«1.5.1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен хәрби-учет белгечлекләре буенча белгечләр әзерләү өчен автомәктәпнең укыту-матди базасы булган җир кишәрлекләренә карата салым ставкасын 0,05% ка кадәр киметү».

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru (Интернет челтәрендә) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссия рәисе А. В. Соловьевка йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**